**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Яңасала авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2019 елның 30 декабре** **№139**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2016 елның 20 апрелендәге 22 номерлы «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге «муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында” карарына үзгәрешләр кертү турында»**

«Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2016 елның 20 апрелендәге 22 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, һәм 15 статьяның 2 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, теркәлүне раслый торган документ;".

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Яңасала авылы, Үзәк урам, 1 нче йорт;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Шәпкә авылы, Клуб урамы, 14 йорт,шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми

порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Яңасала авыл җирлеге**
**Башлыгы, Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Яңасала авыл җирлеге Советы рәисе** **И.Х.Шиһабеев**